**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«БОРДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«05» декабрь 2025 ел № 3/5

## Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлегендә муниципаль вазифаны даими нигездә биләүче затларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү системасы турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары (2018 елның 24 апрелендәге 281 номерлы, 2018 елның 14 июнендәге 481 номерлы, 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы, 2018 елның 29 декаберендәге 1320 номерлы, 2021 елның 17 ноябрендәге 1087 номерлы, 2021 елның 13 декабрендәге 1222 номерлы, 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы, 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы, 2024 елның 24 июнендәге 451 номерлы, 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы, 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), авыл җирлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлегендә муниципаль вазифаны даими нигездә биләүче затларның һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү системасы турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Советының 2023 елның 18 февралендәге 25/1 номерлы карарына (аңа Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге Советының 2024 елның 5 июнендәге 43/3 номерлы; 2024 елның 11 июлендәге 45/1 номерлы; 2024 елның 6 декабрендәге 50/4 номерлы; 2025 елның 28 апрелендәге 56/1 номерлы, 2025 елнын 31 маендагы 57/1 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 1 пунктчасында «15 389» саннарын «16 928» саннарына алыштырырга;

2 бүлек 1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль вазифаны даими нигездә биләүче затның (җирлек башлыгы) хезмәтенә түләү айлык акчалата бүләкләү формасында башкарыла:

| Вазифа исеме | Акчалата түләү күләме (сумнарда) | Акчалата кызыксындыру түләве (сумнарда) |
|---|---|---|
| Җирлек Башлыгы | 23 201 | 29 930(15,48) |

4 бүлек 2 пунктта «15 389» саннарын «16 928» саннарына алыштырырга, «2025 елның 1 маеннан» сүзләрен «2026 елның 1 гыйнвареннэн» сүзләренә алыштырырга;

4 бүлекнең 3 пункты 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

| Вазифа исеме | Хезмәткә түләүнең 12 төркеме |
|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 23 192 |
| Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары | 22 515 |
| Әйдәп баручы белгеч | 18 791 |
| 1 категорияле белгеч | 16 928 |

2. Әлеге карарны интернет ммәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнвареннэн барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы Р.Н.Абдульманова